Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



3

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ МАРТ * 2021 * КАЗАН

13

1 ПОДЪЕЗД

Аның каравы,
безнең ишегалдында
парковка мәсьәләсе
юк!

Александр ШУЛЬПИНОВ

Алмаз ХӘМЗИН

БӘЙРӘМЕГЕЗ КОТЛЫ БУЛСЫН!

Капка төбе. Кызып-кызып
Сөйләшәләр ике карт:
– Котлыйсыңмы карчыгыңны
Житкәч 8 нче Март?!.

Чәчәк сатып аласыңмы,
Үбәсеңме кочаклап?
Нәрсәләр пешерәсең аңа,
Итле ашмы, борчаклап?

Иданнәрне юасыңмы,
Тузаннар сөртәсеңме?
Пәп итеп уятасыңмы,
Торганын көтәсеңме?..

Яратам, дип әйтәсеңме,
Онытасыңмы әллә?
– Әйтәм инде, ул бәйрәм бит,
Елга бер генә килә.

Иданен дә юам инде,
Ә нигә, ник, юмаска?..
8 нче Март көнне,
Юдым, дип мактанмаска?

Чәчәген дә алып кайтам,
Бер канәфер жәлмени?..
Ну, чурт с ним инде, пускай,
Пенсиям бераз кими...


Теш казнасын алып киләм,
Суга салган савыттан.
Ходай Тәгаләгә рәхмәт,
Өзмәс әле саваптан!

– Син дә әйбәт егет икән,
Мин дә әле бик хәйран!
Икебез дә 80 яшьтә –
Монысы да зур бәйрәм!

Карчыкларыбыз исән-сау,
Гөрләшеп яшәр чаклар!
Бәйрәмегез котлы булсын, –
Дип дәшә сезгә Картлар!



Александр ШУЛЬПИНОВ



–Балконнан ни чәчкән булсалар, шул үсеп чыкты!

ШОМБАЙ *болай диде...*



Хөрмәтле Чаян! Телевидениедән тәмәке тартуны күрсәтү тыелганга инде бер ел үтте. Зәңгәр түтен арасыннан сериаллардагы персонажларны күреп тә булмый. Дөрес, экран астында «фильмда тарту күренешләре бар» дигән язу чыга. Ә 1 февральдән тагын бер карар кабул ителгән – иҗтимагый челтәрләрдә сүгенү сүзләре файдаланмау турында. Тик нишләптер халык тагын да катырак сүгенә башлады. Нәкъ менә киресенчә! Хәтта Роскомнадзор да бу закон тиз генә тормышка ашырылмас, дигән белдерү белән чыкты...

В. РӘХИМОВА

ӘГЕРҖЕ

– Законын булса да кабул ителгән, ичмасам, анасын сатыйм! – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач.

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Бөтен ирләр – хайваннар. Хатын-кызларга аларны яхшырак ашату гына кала.

Сәбәпсез алдамаган хатыннарны намуслы дип йөртәбез.

Ирләрнең ни дәрәҗәдә ялганга мохтаҗ булуын хатыннар белән табиблар гына белә.

Хатын-кыз беркайчан да акча өчен генә кияүгә чыкмый; кияүгә чыкканчы миллионерга гашыйк булырга акылы җитә аның.

Әгәр дә ир белән хатын бергә яшәми торган булса, уңышлы никахлар ешрак очрар иде.

Сөюсез никах булган урында никахсыз сөю булыр.

Ялганнарга хатының белән полицейскийга гына ярый, ә калганнарга дөресен сөйләргә кирәк.

(сөю белгечләре мәҗлесендә язып алынды)



Михаил ЛАРИЧЕВ



Николай ВОРОНЦОВ



Болганчык еллардан сәлам

Полиция – йөзләгән маскасыз йөрүчеләрне, ә росгвардия, өсләренә очкан пластмасс стаканнарга исе китмичә, санкциясез митингта катнашучыларны бәйләгән чакта республикадагы криминал әкрен генә яңарыш кичерә, "кан яңарта". Күптән түгел Казанның үзәгендә диярлек, Павлюхин һәм Назарбаев урамнары киселешендәге ресторан каршында ике дистәләп егет канга батып сугыша. Полиция килеп җитүгә бәрелештә катнашучылар инде качып өлгергән була. Башта бу хәлгә гади урам вакыйгасы дип карыйлар: имеш, кайнар канлы яшүсмерләр, нәрсәдер бүлешә алмыйча, йодрыкларын эшкә җиккән. Ләкин шул ук вакытта зыян күрүчеләрдән полициягә бернинди мөрәҗәгать булмаган; ресторан хезмәткәрләре бернинди анык аңлатма бирә алмаган, ә сугыш чукмарлары исә мыштым гына янәшәдәге ишегалларына сеңгән. Бу шикле хәл вакыйгага башкача карарга мәҗбүр иткән. Бөтен билгеләре буенча туксанынчы елларны хәтерләткән бу вакыйга: ике төркемнең кара-каршы торып сугышуы да, шаһитларның телләрен тыеп торулары да, полиция белән бәйләнергә теләмәү дә – "егетләрчә" түгел чөнки...

Һәм бу берданбер очрак түгел. Ел башында "Казан феномены" заманнарындагы кебек, бер сугышны булдырмый калганнар иде инде. Ул чакта, әзерләнгән бәрелеш турында мәгълүмат алу белән, хокук органнары тарафыннан кырыклап кеше тоткарлана. "Сугышчы"ларның машиналарында чын арсенал – дистәләгән арматура таяклары, ясалма пистолет табыла. Ул вакытта, бәхеткә, куркыныч вакыйгага башланганчы ук киртә куела. Ә менә Яшел Үзәндәге биш йөзләп кеше катнашкан, металл чыбыклар белән коралланган ике криминаль төркем арасындагы кан коюны полиция никтер күрми кала. Дөрес, бәрелештә катнашкан алты кешене, ни булса да, тоткарлый алалар. Аларны "хулиганлык" статьясы буенча җиде елга кадәр иректән мәхрүм итү көтә. Анысы да гаепләре исбатланса, әлбәттә...

Чаллыда да, уҗәтләнеп, яшьләрнең җинаятьчел төркемнәре баш күтәрергә маташа. Аларның артларында кем торганын уйлап торасы да юк – күптән түгел зонадан кайткан әлеге дә баягы "авторитет"лар. Шәһәр халкы "Белята" һәм "48 комплекс" төркемнәре арасында булган зур бәрелешне әле дә хәтерлиләр. Шунысы кызык, ул бәдбәхетләрнең хәтта иҗтимагый челтәрләрдә "батырлыклары" белән мактана торган үз битләре дә бар...

Җәмгыятьтә нәрсә эшләнгәнен аңлар өчен әллә кем булырга да кирәкми: төрле оешкан җинаятьчел төркемнәрнең активлашуы бу. Болганчык туксанынчы еллардагы кебек, ачык идеология, тормыш перспективаларыннан мәхрүм ителгән яшьләр, тормышта җылы урын эзләп, тагын кыргый "көтү"ләргә берләшә. Ә ул "җылы урын" ешрак чәнечкеле чыбык артында булып чыга.

Заманында хокук саклау органнары күп кенә бандаларны тар-мар итеп, аларның башлыкларын тиешле урынга кертеп урнаштырганнар иде инде. Бүген алар ирекτә, һәм хәзер яшьләрне төрмә романтикасы белән сугарылган җинаятьчелек юлына тартып, урамнарда тагын хуҗа булырга телиләр.

Полиция хезмәткәрләре дә йоклап ятмый, әлбәттә. Күптән түгел алар "Казан феномены" эшен дәвам итәргә маташучыларга "кайнар сәлам" юлладылар. Форма кигән таза егетләр давыл кебек Яңа Савин районындагы законсыз ларёк һәм шиномонтаж будкаларын айкап чыктылар. Криминалның оешу нокталары кискен рәвештә юкка чыгарылды. Бу, әлбәттә, "браток"лар акча каера торган урыннарның кечкенә өлеше генә. Ләкин катгый ишарә ясалды диярга була. Ул кабул ителерме, юкмы – монысын вакыт күрсәтер...

Рамил ГАТАУЛЛИН

Александр АЛЁШИН



• • •

Аз урласаң – зур срок аласың. Күп урласаң – моның өчен берни дә булмый. Ә менә башкалардан уздырып, бик күп урласаң, ул чакта инде башкаларны утырта аласың!

• • •

– Сезне ни өчен утырттылар?

– Беләсезме, берзаман дәүләтнең нәкъ мин ясап яткан кебек, акча чыгаруы ачыкланды....

Вячеслав ШИЛОВ



•••

Әти икенче тапкыр туган көнемә домино һәм нард уены җибәргәч, аның космонавт булуында шикләнә башладым...

•••

Күршенең машинасын урлап китүләрен күрү белән, югалып калмадым: урамга йөгереп чыктым да, ул урынга үземнекен куйдым.



Иван АНЧУКОВ

Александр Брюханов

Хәмерша бандасы

Куптән түгел Кисек Имәндә шәһәр тарихында иң эре булып саналган оешкан җинаятьчел төркем юкка чыгарылды.

Мөстәкыйль һәм мөстәкыйль булмаган матбугат чаралары белдерүенчә, бу төркемгә әлеге кешеләр кергән:

– бандага аны эчтән таркату максаты белән кертелгән һәм төркемдә "төнге күбәләкләр" белән идарә итүче Тикшерү комитетының төптән тикшерү бүлеге тикшерүчесе Чәпиев;

– легенда буенча йорт карагы, Кисек Имән төркеменең Рәсәйдә тыелган бөтендөнья террор үзәкләре белән элемтәсен күзәтүче – Төп үзәкнең үзәк идарәсе капитаны Букәнев;

– соңгы ун ел эчендә юкка чыккан полиция машиналарының язмышын ачыклау өчен җинаятьчел төркемдә автомобиль карагы булып эшләгән ЮХИДИ майоры Таякшин;

– өлкәдә дефицит даруларның юкка чыгу юлларын ачыклау максаты белән банданың һәм наркопритонның башлыгы янында йөрәк дусты булып торган баш шәфкать туташы Уколова;

– үзе вак урлаулар белән шөгыльләнеп, бандага кертелгән башка закон сакчыларының гамәлләрен законлы булуын күзәтеп торучы шәһәр прокурорының урынбасары Тәртәев; .

– "общак" тотучы вазыйфаларын үтәп, җинаятьчел төркемнең полиция даирәләре белән элемтәләрен капшау белән шөгыльләнгән исполком рәисе урынбасары Сәмәншин.

Ә Кисек Имән бандасының башлыгы булып төзәлмәс эчкече буларак даны чыккан, "Хәмерша" кушаматлы Хәйбул торган. Ул бу урынга төркемнең гомуми җыелышында туры һәм яшерен тавыш бирү аша сайланган булган.

Җентекләп һәм төпләп әзерләнгән махсус операция нәтиҗәсендә Хәмерша бандасы юкка чыгарылган, ә аның башлыгы судка кадәр хатынының ышанычлы кулларына тапшырылган. Барча операциядә катнашучылар яшерен Указ буенча кыйммәтле бүләкләр һәм Грамоталар алачак.

Хәзер Кисек Имән кешеләре иркен сулап, тынычлап яши алачаклар. Чөнки шәһәрдәге башка җинаятьчел төркемнәр ваграк та һәм оештыру ягыннан да зәгыйфьрәк.

•••

– Полиция?! Әллү, полицияме бу?!
– Әйе, тыңлыйбыз сезне...
– Күрше тагын исерек, хатынын кыйный!
– Кыйнаса соң...
– Ул бит хатыны артыннан балта белән чабып йөри һәм мондагы бөтен кешене үтерәм, дип яный!
– Янаса соң...
– Аның бит күзләре шашынган кешенеке кебек!
– Булса соң...
– Ул бит әле "бөтен полицейскийлар да бәрәннәр", дип акыра!
– Аңлашылды! Хәзер килеп җитәбез...



• • •

Сәер дә инде бу хатыннар... Әниләре белән яшәгәннәрне күрәселәре дә килми, ә менә хатыны һәм балалары белән яшәүчеләр белән – рәхәтләнеп очрашалар.

• • •

Әйтегез әле, доктор, бу җитди авыруммы?

– Шулай да мин сезгә яңа сериаллар карый башларга тәкъдим итмәс идем...

• • •

Кызы сорый:

– Әти, нигә урамдагы күгәрченнәр барысы да зурлар, берсе генә дә бәләкәй түгел?

– Алар безнең байлар кебек – балаларын чит илләрдә үстерәләр, ә ашап күбенергә һәм кәкәй итәргә монда кайталар.

• • •

Әллә ни ерак булмаган киләчәк. ЖКХ реклама хезмәте:

"Фатирыгыздан чыкмыйча гына, лифтта йөрер өчен билет алыгыз!"

• • •

– Яңа Айфон алу өчен гаять зур чиратлар булуын белгәч, минем әти көлеп куйды.

– Ә нигә?

– Чөнки кайчандыр өенә кертелергә тиешле телефонын ул 10 ел чират торып көткән икән.

• • •

Кибеттә:

– Гафу итегез, сез бит миңа кичә голланд сыры урынына рәсәйнекен саткансыз!

– Ә сез, нәрсә, аның белән сөйләштегезме әллә?

• • •

Кәрәкә – кәрәкәгә:

– Син миңа, әлбәттә, ышанмаска мөмкинсең, ләкин кармагыннан ычкынган теге балыкчы 90 килограммнан ким түгел иде.

• • •

Әгәр сез бер генә дә кроссворд чишә алмыйсыз икән, димәк, сез – Достоевский романындагы биш хәреф.











БЕР ФИКЕРГӘ – ИКЕ КАРАШ

Рашат Низами: Кемдер уйлаганча, милли халыклардан "россиян" ясар өчен патшачылык заманындагы губернаторларны кайтару кирәк икән...

Алмаз Хәмзин: Моның өчен хәзер Думада бер депутатның "пышылдавы" да җитә, Рашат дус.

Р. Н.: Элек СССР вакытында тимурчылар отряды бар иде, ә хәзер Кремль эргәсендә Тишковчылар отряды мәш килә! Максатлары ачык...

А. Х.: Халыкка каршы булган гамәлләр хәзер ап-ачык, яшереп тормыйлар һәм халыкның үз кулы белән эшлиләр...

Р. Н.: Путин СССРга мең рәхмәтләдер, ул Аны менә дигән чекист-полководец итеп үстерде бит...

А. Х.: Без дә шул чорда чыныктык бит югыйсә...

Р. Н.: Кешенең бәләкәй генә башына тау чаклы "этлек"ләр дә сыя!

А. Х.: Этнең башы кечкенә булса да, тау чаклы мәрхәмәтлерәк бугай...

Р. Н.: Дошманның зурысы, бәләкәе булмый.

А. Х.: Дусның да шулай.

Р. Н.: Илдә шизофрения чире дә тарала башлады. Моңа каршы вакцина уйлап табарга җыенмыйлар микән?

А. Х.: Юк. Ул чир гади халыкныкы түгел...

Р. Н.: Кеше – Аллаһ бүләге, ләкин ул үзен ясый, яхшыга таба иҗат итә белергә дә тиеш.

А. Х.: Ләкин Ул безне кемгә бүләк иткәнен белмәде бугай шул...

Р. Н.: Галактикада маймыллар планетасы бар микән?

А. Х.: Безнең планетадан башкасы юктыр, мөгаен...

Р. Н.: Бай яки хәерче булуның морале дә, статусы да юк сыман...

А. Х.: Берәүнең бай булуы, күпләрнең хәерчелегенә бәйле.

Р. Н.: Әгәр коронавирус килеп чыкмаса, аны барыбер уйлап табарлар иде.

А. Х.: Уйлап тапканнан килеп чыккан зәхмәт бит инде ул.

Р. Н.: Әгәр алдашу конкурсы үткәрелсә, беренчелекне кибет һәм базардагы үлчәү тәлинкәләре алыр иде, мөгаен.

А. Х.: Юк, Рашат дус, дөрес әйтмисең, аны бөтен халык белә..

Бәйрәм котлаулары

Заманалар үзгәрде. Бар кешенең дә смартфоннары бар. Хәзер нинди бәйрәм дисәң, Ватсаптан гына кара. Азапланып язып торасы да юк котлауны. Интернеттан әзер сүзләрне җыеп җибәрәсең дә, эше бетте. Берсе җибәргәнне син тагын ун кешегә таратырга мөмкин. Котлаулар шулай әйләнеп йөри бәйрәмнәр беткәнче.

Балачактан исемдә калган котлаулар бөтенләй икенче. Кибеткә барып открыткалар, конвертлар җыя торган идек. Аннары туганнарга, дусларга үз кулыбыз белән җылы сүзләр яза идек. Шулай ук, үзебез дә, бәйрәм җиткәч, почта ящигын ачып, открыткалар, хатлар ала идек... Әйе, аларны кат-кат укып, саклап, җыеп куя идек.

Кызганыч, хәзер бәйрәм белән тәбрикләүләрнең җылысы юк, хәтердә дә калмый. Чөнки бераз вакыт үткәч, смартфонны чистартабыз. Анда бит урын күп түгел. Кем котлаган, кем нәрсә язган – онытыла. Шулай, гаджетлар заманасы дисәк тә, кадере аз икән шул игътибарның. Шул яңалыклар карап, шалтыратышып торырга гына ярый.

Виртуаль дөнья шаукымына ияреп яшәү уңаеннан тагын бер нәрсә әйтәсем килә. Элегрәк вакытта без газета-журналларга бик күп язылдык. Ошаган статьялар, рәсемнәр киселеп, аерым бер альбомга ябыштырылды. Хәзер анысын да эшләмибез. Укыдык... онытылды...

Киләчәк – интернетта, диләр. Шулай инде анысы, заманасы шул. Тик менә кулыңа әле генә басылган җылы һәм уңайлы газета, журнал тотудан да рәхәт нәрсә юктыр дип уйлыйм мин.

Гүзәл НӘБИУЛЛИНА


БӘЙРӘМ ЕЛМАЮЛАРЫ

Михаил ЛАРИЧЕВ



Валерий ТАРАСЕНКО





Валерий ТАРАСЕНКО

Шәйхи МАННУР

ЧӘЧЛӘРЕ ЧӘЧКӘ БӘЙЛӘНГӘН

«Урамнардан узсам да мин,
Яланнарга чыксам да мин,
Очратамын сине һаман да,
Менә бүген тагын монда, –
Очраштык без ял йортында,
Сөю теләп йөрәк янганда.

Сөям сине,
Сизәсеңме,
Синең өчен башым әйләнгән.
Без мәңгегә
Булыйк бергә,
Чәчләр безнең чәчкә бәйләнгән...»

Шулай сайрый матур егет,
Ә кыз аны тыңлый көлеп
һәм башына карый шул чакта.
Ә егетнең хәле яман:
Башында бер чәч калмаган –
Ялтырап ла тора кояшта.
«Ха-ха, ха-ха,
Җаным, Вафа,
Башың пеләш икән, беләмсең?
Шулай булгач,
һай сандугач,
Чәчләр ничек чәчкә бәйләнсен?..»

Виктор ФЁДОРОВ



Максим СМАГИН



Михаил ЛАРИЧЕВ





КЕРЕМЛЕ АМНЕЗИЯ

Татарстанның Кайбыч районында хәтерләре начар булган түрәләрне ачыклаганнар. Муниципаль белем бирү оешмалары җитәкчеләренең керемнәре һәм чыгымнары турында мәгълүматны өйрәнеп, 19 кешенең үз керемнәрен яшерүе яки онытуы, банк счетлары турындагы мәгълүматларны дөрес күрсәтмәве яки тиешле белешмәләрне дөрес тутырмаулары билгеле булган. Дүрт чиновник кисәтүләр белән котылган, ә унбиш башлыкка шелтә белдерелгән.

МУЗЕЙЧА ТУРАУ

ТАССР төзелүенең 100 еллыгына хөкүмәт ТР Милли музеена «Татарстан тарихы борынгы заманнардан һәм безнең көннәргә кадәр» дигән күргәзмәгә заказ бирелде. Әлеге максатка 50 миллион сумнан артык акча каралган булган. Әмма экспозиция кысаларында музей җитәкчелеге тарихи артефактларны гына түгел, бүлеп бирелгән акчаларның «турау» сәләтен дә күрсәткән. Тикшерүчеләр 3 млн. сум акчаны тапмаганнар. «Бюджет акчаларын максатчан файдаланмау»да кемнәр катнашканлыгын хәзер прокуратура ачыклый.

РИШВӘТЧЕЛЕК

19 нчы Казан колониясе башлыгы урынбасары һәм тоткыннарның хезмәт адаптациясе үзәге башлыгы Ринат Нәбиев үзе статья белән эләккән. Аның шефлыкка алынган хезмәткәрләре хезмәткә җайлашкан арада, башлык урынбасары урларга җайлашкан. Колония җитәкчелеге 380 табут ясау турында килешү төзегән. Тик соңрак «контрактны өзлексез үтәү һәм заказ бирүче мәнфәгатьләренә гомуми яклау» өчен алардан акча һәм смарт-сәгать таләп иткән. Барлыгы – 160 мең сумлык. Ә баш тарткан очракта, товар җитештерүне туктатып тору белән янаган. «Яклаучыны» сак астына алганнар.

ИТӘКЛЕ ЧИЧИКОВ

Тагын бер Чичиковны «үле җаннар»ны эшкә урнаштырган өчен хөкем иткәннәр. Бу юлы үлемсез әдәби герой образын Чаллының сукбайлар үзәгенең элеккеге директоры уйнап карарга булган. Аның эшеннән килгән зыян 2,4 миллион сумнан артып киткән, моның өчен җитәкче шартлы рәвештә ике елга ирегеннән мәхрүм ителгән.

Дамир МОРТАЗИН

ДУСЛЫК ХАКЫНА...

Жыр һәм бию институтының ике урында берьюлы эшләүче җырчы-доценты – Салатов кабинетына кайчандыр эстраданы гөрләтеп торган Тархунов килеп керде.

– А-а-а, якташ! – дип, шат йөз белән каршы алды аны доцент. – Күптәннән күрешкәнебез юк! Нинди җилләр ташлады?

Шатлыкның чиге булмаганын белдереп, кочаклаштылар, куллары белән җилкәләрен кыйнаштыргаладылар. Кәнәфиләргә җәелеп китеп, яланаяклы малай чакларын искә төшерергә керештеләр һәм, берочтан, шәһәрдәге яшь-җилкенчәк вакытларын.

– Хәтерлисеңме, син минем концертларның алып баручысы идең, безнеңчә әйткәндә, телбистәсе... – дип төрттереп көлеп куйды ул. – Онытмадыңмы, сине кем батчаклыктан тартып чыгарып кеше итте?

– Хәтерлим, хәтерлим, Югары Биләштә концерт вакытында исерек килеш сәхнәдән егылып төшкәнеңне, – дигән сүзе белән ачуын кайтарды Салатов. – Ә чыраеңа ничек ямады тегенең ире... ничек әле исеме?.. Розаныңмы, Флораныңмы... ну... биючеләрнең?

– Эх яшьлек! Кем уйлаган, беркем белмәгән лыгырдык һәм авыл гармунчысы профессор булыр дип! Беләсеңме, иң кыска мәзәк нинди: Салатов – профессор!

– Тагын да кыскарагы бар әле аның: Тархунов – җырчы! Әйт, ни өчен килдең?

– Эш бар, – шундук җитдигә әйләнде Тархунов. – Берәүне күтәрергә кирәк... ни... җырчы кызны...

– Сөяркәңнеме? – дип күз кысты профессор. – Әле һаман туймыйсың икән... Күптән түгел генә өйләндең түгелме соң кабат...

– Монысы күпкә яманрак! – диде җырчы, авыр сулап. – Яңа тёща сәхнәгә ыргыла! Тавышы да, ишетүе дә, чырае да юк, ә минминлеге – бөтенебезгә җитә! Кемнәр генә юк безнең эстрадада, мин алардан ким мәллә – мин дә фонограммага авыз ачып торырга оста... Күзгә томау кебек ябышты бит! Фонограммасын яздырып бирергә туры килде – җырының эчтәлегендә: авыл, чишмә, карт әни... Үзең беләсең инде... Ә аның өчен бер җырчы кыз җырын яздырды – син аны белмисең... Шәп тавышлы, диапазон, тембр, төсләр, обертоннар! Карале, мин тёща өчен сәхнә кушаматы уйлап таптым – Азалия. Җен алгыры!

– Ә миннән нәрсә кирәк? – дип сорады сагаеп Салатов.

– Чүп кенә! Иске дуслык хакына, керт әле тёщаны концерт программасына. Берәү ким, берәү артык – ичмасам, миннән тайпылмасмы... Туйдым шуннан...

Салатов бик тирән уйга чумган кебек хәлгә керде.

– Азалия, дисеңме... Ул очракта Розалияне читләштерергә туры килер... Ну, нәрсә, ни генә эшләмәссең якташ хакына. Карале, җырчының исеме ничек әле?

– Кайсының?

– Тёщаңның фонограммасына җырлаган...

– Белмим... – Тархунов каушап калды.

– Их, чын талантларны бәяли белмибез! – дип чыгырыннан чыкты профессор. – Җыен чүп басты эстраданы, әйтерсең лә Самосыр чүплеге – брат, сват, сөяркә, җитмәсә, менә тагын тёща... Тап та алып кил миңа аны...

– Тёщанымы?

– Юк, җырчысын!..

– Ярар, табармын!

Салатовның йөзендә канәгать елмаю сизелеп китте. "Бер аспиранткага фонограмма яздырырга кирәк булыр, – дип уйлады ул. – Эстрадага өлгерде чибәркәй – сөйкемле, зифа буйлы, дәртле... Сәхнә өчен тагын нәрсә кирәк? Хатын гына сизә күрмәсен..."



Виктор ФЁДОРОВ



Юрий КУХАРЕНКО







Рамил ИСЛАМОВ



Диета

Безнең подъездда лифт эшләми башлады. Бишенче катка менеп тын алгач, диетага утырырга кирәк дигән фикергә килдем. Биш кило чамасы югалтсам, организмым өчен менә дигән булыр. Интернетта диетасын да таптым: иртәнгә бер чынаяк кофе, төшкә — яшел суган белән сыек ботка, кичке аш урынына – бер стакан кефир. Бернинди камыр ашлары, бернинди итле һәм татлы ризыклар турында авызыңны да ачма!

Беренче көн бик шәп үтте. Дөрес, иртәнге якта бераз баш әйләнде, көндез эч быгырдап интектерде, ә кич белән хәлсезлектән чак кына аңымны югалтмый калдым. Төнлә коточкыч төш күрдем – кайнанам мине көчләп пәрәмәчләр һәм чәкчәк белән сыйлый икән.

Салкын тиргә батып уяндым һәм "иртәнге аш"ны ашарга утырдым. Калтыранган кулларым белән авызыма шикәрсез кофе китергәндә күрше бүлмәдән хатынның тавышы ишетелде: "Бер пешкән йомырка белән бутерброд ашасаң, артык булмас!" Бу мәсьәләдә ул миннән күпкә тәҗрибәлерәк — гомер буе исенә төшкән саен, ябыгам дип, диетага утырып карый. Мин ризалаштым.

Төштән соң иске дусны очраттым. Диетада икәнемне белгәч, ул миңа болай диде:

– Иң шәбе – бәрәңге ашау! Миңа таныш врач киңәш итте. Анда калорияләр бик аз... Иң мөһиме – кыздырганда көйдермәскә һәм тозны чама белән салырга кирәк!

Белгән кешеләрнең киңәшләренә ихтирам белән карарга өйрәнгән, шуңа күрә кич белән корсак тутырып кыздырылган бәрәңге ашадым.

Икенче көн күпкә җиңелрәк узды. Иске дусның танышы шалтыратты һәм өр-яңа ит диетасы турында хәбәр итте.

– Син белми идеңмени? – дип гаҗәпләнде ул. – Бөтен йолдызлар шуның белән җенләнә бит! Әнә, кара, Киркоров ничек ябыкты! Ә Элвин Грей? Аны тиздән сәхнәдә күреп тә булмаячак...

«Әгәр Киркоров та булгач...» – дип уйлап куйдым мин һәм якындагы шашлычныйга юл тоттым. Каршымда ямансу кыяфәтле бәндә утыра иде. Ул миңа карап алды да авыр сулап куйды:

– Итне — сырасыз?... Йә, йә...

– Мин диетада, – дип акландым.

– Ул чакта бигрәк тә! – дип җанланды бәндә. – Сыра майны тарката һәм ашказаны эшчәнлегенә ярдәм итә! Доктор Малышеваны карарга кирәк...

Берсүзсез ике бокал сыра алдым.

Диетаның өченче көне иң авыры булып чыкты. Ләкин организм инде үзгәрешләргә ияләнгән иде. Минем диета турында белгәч, күрше үзенең бабасы турында сөйләде. Ул бары тик камыр ашлары белән генә туклана икән һәм инде кырык килограмм югалткан. Бу могҗиза турында ишеткәч, бер кәстрүл макарон пешердем һәм аны ипиләп ашап та бетердем. Бабай ни эшләгәнен белә ул! Кырык кило югалтып, исән калган булса, әлбәттә.

Шулай да бу авыр көнне исән калдым. Иртән ике йомырка, ит белән кыздырылган бәрәңге ашап, шикәрсез кофе эчкәннән соң, таныш сантехник Шәрапов киңәш иткән диетик шәраб эзләргә чыгып киттем. Ул мондый нәрсәләрнең рәтен белә инде...

Диетага килгәндә, аны әлегә кадәр тотам, һәм аны яңа танышларымның киңәшләре белән тулыландырып торам. Барчасын да игътибар белән тыңлап, мыегыма чорный барам, һәм ул киңәшләрне тормышта файдаланам.

Әйтергә кирәк, бишенче катка менгәндә тыным кысылмый башлады. Подъездда, ниһаять, лифт эшли башлады...

Абау!

БРАЗИЛИЯДӘН СӘЛАМ

Казанның Мәскәү районындагы ЖКХ идарәче компаниясе бар дөньяны гаҗәпләндерергә булган. Декабрь белән чагыштырганда сизелерлек арткан счётның арткы ягында Бразилия язучысы Пауло Коэльоның бөтен нәрсәдә гүзәллек күрә белү турындагы сүзләре язылган.

«Көләләр дә инде бездән!» – дип уйлагандыр бу гыйбарәне укыган казанлылар.

Әмма торак хуҗалыгында эшләүче дөнья әдәбияты белгечләре моның белән генә туктарга җыенмыйлар һәм безгә бөек әдипләрнең башка уңай фикерләре белән шатландырырга телиләр.

СҮЗ ИРЕГЕ

Санкт-Петербург полициясе рөхсәт ителмәгән митингта лозунглар кычкырып торган өчен ир кешене тоткарлаган. Ишетми, сөйләшми торган бу бәндәнең кибеткә ипигә барган чагы булган. Ул куллары белән полицейскийларга нәрсәдер аңлатырга маташуына карамастан, аны берничә сәгать камерада тотканнар, аннары зиһене чуалып беткән инвалидны судка илтеп тапшырганнар. Анда, бөтен булган дәлилләрне истә тотып, тәртип бозучыны 5 мең сум штрафка тартканнар.

КЫЙНАГАНДА АВЫЗЫҢНЫ ЙОМ

Самара өлкәсенең Зольное авылында яшәүче хатынга ире кыйнаганда артык нык кычкырган өчен штраф салганнар. Тавыштан туйган күршеләре полиция чакырганнар, ә килеп җиткән хокук саклау хезмәткәрләре аны тынлык бозуда гаепле дип тапканнар. Икенче көнне эшне административ комиссиягә тапшырганнар, ә анда шау-шу сәбәпчесенә 500 сум штраф билгеләгәннәр. Бичара хатын үзен кыйнаганга күрә кычкырганын суд аша аңлатырга тырышып караган, ләкин комиссия карарын үзгәрешсез калдырганнар.

ХЫЯЛЛАР ТОРМЫШКА АША

Мәскәүдә яшәүче 14 яшьлек яшүсмер, дискотекаларда акылын җуйган яшьтәшләреннән аермалы буларак, метрода эшләү турында хыялланган. Хыялына бер генә минутка булса да кагылып карау максаты белән ул махсус чын операция уздырган. Тавышын үзгәртеп, "Хорошевская" станциясендәге дежурныйга шалтыратып, аңа стажёр килүе турында хәбәр иткән. Шук малайны берничә сәгать буе җир асты транспорты серләренә өйрәткәннәр. Әмма бераздан полиция аның әзенә төшкән. Метрога гашыйк егетнең әти-әнисенә карата административ беркетмә төзегәннәр, ә аның үзен балигъ булмаганнарның эшләре буенча комиссиясенә учётка куйганнар.









ШУК КҮКЕ

Авылда яшәгән һәрбер кешенең исем кебек кулланыла торган кушаматы була. Кайберәүләрнең кыяфәтендә нинди дә булса җәнлек сыйфатлары табыла: Бүре Хәмит, Төлке Гафият... Икенчеләрнең исә фамилияләрен генә кыскарталар. Берәүләрнең кушаматлары бабаларыннан килә, ә икенчеләре аны үзләре "эшләп ала". Ләкин аларның иң кызыклылары булып берәр нинди вакыйга белән бәйләнгәннәре санала. Мирзаһитның кушаматы нәкъ шундыйлардан була...

Мәктәптә хезмәт дәресләрен кырыс холыклы, ләкин үзенчә гаделлек сөючә Габдулла абый алып бара. Үзе алтын куллы булган укытучы балаларны ышкы, өтергә, пычкы белән эшләргә өйрәтә. Берзаман малайлар шаярышып китәләр, станоклар арасында йөгерешеп, бер-берсенә йомычка ыргытып уйный башлыйлар. Әлбәттә, сыйныфтагы иң шук балалар – Мирзаһит та башкалардан калышмый. Әмма Габдулла абыйның кашларын җыерып, өстәлгә бер сугып алуы була – барысы да шым була. Мирзаһиттан башка.

– Габдулла абый, мин монда, күкү! – дип тавыш бирә ул үз урыныннан. Укытучы аңа борылу белән, Мирзаһит станок астына кереп китеп, аның икенче ягыннан килеп чыга.

– Габдулла абый, күкү! – дип кычкыра тагын Мирзаһит. Укытучы инде мондый кимсетүгә түзә алмый, һәм аны куып тотмакчы була. Ләкин Мирзаһит тагын юкка чыга һәм бер мизгелдән тәрәзә янында пәйда була.

– Габду... – дип башламакчы була ул сүзен, ләкин кинәт кенә абынып китеп, башы белән бәрелә һәм идәнгә чәчрәп барып төшә. Аны классташлары әйләндереп ала.

– Су китерегез, су! – дип кычкыра Габдулла абыйсы. Мирзаһит әкрен генә аңына килә һәм күзләрен ача. Карашын томалаган томан аша ул укытучысының куркынган йөзен төсмерләп ала.

– Габдулла абый, мин монда, күкү! – дип пышылдый ул көч-хәл белән. Классташлары тәгәрәп көлә. Шуннан алып аңа "Күке" кушаматы ябышып кала...

ҮЗЕ ТУРЫНДА УЙЛАМАГАН

Мирзаһит йорт хайваннарын бик ярата һәм алар да аңа шулай ук җавап бирәләр: атлар Мирзаһитны күрү белән кешнәп куя, сарыклар артыннан ияреп йөри, ә үгезләр ихтирам белән баш ия. Тик менә аның беркайчан да эте булмый.

– Нигә син эт тотмыйсың, күрше? – дип сорый аннан берзаман авылдашы Хәлил. – Үзең беләсең, эт ул авылда дус та, ярдәмче дә, сакчы да бит.

– Бу турыда уйлап карарга кирәк, – дип җавап бирә көтелмәгән сораудан бераз югалып калган Мирзаһит. – Күз алдыңа китер: минем янга кунак килде һәм керергә тели, ди. Ә эт өреп, аңа ыргыла башлый. Кеше уйлап тора-тора да китеп бара. Миңа беркем дә йөрми башлаячак бит!

– Аны бит чыгып тынычландырырга була, – ди Хәлил.

– Син, нәрсә, нинди тынычландыру ди ул, үземнең гомер буе эттән йөрәгем ярылып тора! – дип җавап бирә Мирзаһит.

– Соң башта ук шулай дип әйтәләр аны! – ди Хәлил көлеп.

Мирзаһит җилкәсен җыерып куя:

– Ә үзем турында нишләптер уйламаганмын...

Зөлфәт ШӘҺИӘХМӘТОВ





ГАЕП ИТМӘГЕЗ – КҮҢЕЛНЕ ЮАТЫП КАЙТТЫМ

Нинди дә булса нәрсәне йөз мәртәбә ишеткәнче, бер мәртәбә күрүең хәерле дигәнрәк гыйбарә бар.

Минем олы кызым Фәридә инде ун елдан артык Мәскәүдә яши. Миңа ел саен анда барырга туры килгәли. Рәхәт инде почетлы кунак булып ятулары!

– Йә, әти, кая барасың, нәрсә күрәсең килә? – диләр.

– Әйдәгез, – мәйтәм, – бүген үк Мәскәү Кремленә барыйк әле?

– Анда керү түләүле икән бит әти, – диюләре була, мин:

– Минем кебек хезмәт ветеранына бушлай ул! – дип җиппәрәм, киерелеп, күкрәк кагып.

Шулай, кияү белән кыз һәм оныгым да минем аркада рәхәтләнеп илебезнең үзәгендә йөреп чыктылар.

– Син алып кермәсәң, гомергә мондый матурлыкны күрү тәтемәгән булыр иде, – дип сөенәләр.

– Ә кәк же! Әтиегез исән чакта кулланып калыгыз яхшылыгымны! – дим.

Йөрибез шулай мәйданда... Бер кызыл бина капкасы янында күрәм – Ленин белән Николай патша басып тора. Ленин – үзенчә, патша – үзенчә киенгән... Яннарында – ике сакчы. Ленинны штык тоткан кызылармеец саклый. Килдем дә, Ленин белән күрешеп:

– Нәрсә, – мәйтәм, – Владимир Ильич, патша хәзер синең дустыңмыни? – дим.

Ул инде үзенчә "р" хәрефен акцент белән җавап бирә:

– Менә дуслаштык әле, Рәсәйне кризистан чыгарып булмасмы дип? – ди.

Мине ерактан оныгым видеокамерага төшерә икән. Боларга – патша һәм юлбашчыбызга уңышлар теләп, киттек алга таба.

Мәйданда бер әби йөри.

– Әби, – мәйтәм, – сезне кем дип белим, – дим.

– Мин, әфәндем, патша Екатерина II булам, – ди. Аерып ала торган түгел – шул формага киенгән.

Ә мин әйтәм:

– Сезне хәтерлибез, сез Казан өчен зур изге эш эшләдегез! Явыз Иван Казанның бөтен мәчетләрен җимереп бетергәч, безгә мәчетләр салырга рөхсәт биргән идегез. Сез утырып йөргән арба музейда әле дә тора, ә копиясе – Проломная урамында. Ул да шулай ук шунда йөреп акча эшли икән.

Шул тирәдә генә, әвеш-тәвеш килеп, бер исерек йөри. Монысы – Распутин булып чыкты. Янына бармадым инде, йә акча сорар...

Аннан Мавзолейга Ленин янына кердек, анда ун метрлап аска төшәсе. Сыек кына яктылык. Минем тел тик тормый бит инде:

– Владимир Ильич, – мәйтәм, – торыгыз әле, тагын безне дөрес юлга кертегезче! Без Сез күрсәткән юлдан адаштык, ахрысы, – дим.

Ә халык әкрен генә көлә.

Көлер шул: елап туйгандыр инде. Халык сүзен тыңлаучы юк хәзер, Ильич янына кереп кенә зарланып чыктым. Гаеп итмәгез!

Сөләйман ШАКИРОВ,
хезмәт ветераны, II төркем инвалид.

КАЗАН

Эрнест ДЫШАЕВ, «Чаян» № 12, 1999



Герман ОГОРОДНИКОВ, «Чаян» № 7, 1995





• • •

Башта үзләре табибларга рәхмәт йө-зеннән коньяк бүләк итәләр дә, соңыннан, аларның язуларын танып булмый, дип зарланалар!

• • •

Яңа сайлаулар алдыннан безнең депутатлар аптырашта калды. Гамәлдә аларның бөтен ахмак закон проектлары инде кертелде, ә кабат яңаларын уйлап табу гаять катлаулы.

• • •

– Әти, ә башка планеталарда тормыш бармы?

– Җирдә дә тормыш булган байтак урыннар бар.

• • •

Миллионлаган югары технологияле эш урыннары булдыру планнарыннан арзан бәрәңге һәм кәкре кыярлар үстерүгә тәгәрәдек шикелле.

• • •

– СССРда бөтенесе ярлы яшәгән, гел нәрсәләрдер җыйганнар – тимер-томыр, кәгазь-картон, гербарийлар, тимер акчалар, маркалар... Ә минә дәвалану өчен нигәдер акча җыймаганнар.

• • •

Карт белән карчык шулкадәр озак яшәгәннәр ди, аларга хәтта оныкларыннан дүрт фатир, өч автомобиль һәм шәһәр читендә мирас итеп коттедж калган.

• • •

– Минә кызык, ни өчен оча торган ир "супермен" дип атала, ә оча торган хатын-кыз – "убырлы карчык"?

• • •

Дусларым туган көнемне белә микән дип тикшереп карарга уйладым һәм аны социаль челтәрләрдә бер атнага алдарак итеп куйдым. Беренче булып ирем котлады...

• • •

Иртәнге алты, шәһәр чите. Сиксән яшьлек әби кар көри. Икенче бер әби, күршеседер инде, сорый:

– Син нәрсә иртә таңнан маташасың?

– Минә "ашыгыч ярдәм" чакырдым, килсәләр – уңайсыз...



Сергей АНДРИАНОВ



Николай ВОРОНЦОВ

Сергей АНДРИАНОВ







Илдар НӘФИЕВ

РЕФОРМА "ЭТЛЕГЕ"

Кадерле "Чаян"! Әйтәләр, чүпне чиләккә никадәр тыгызлап тутырсаң да, барыбер котыла алмыйсың, чыгарып түгәргә туры кила. Ләкин Царицын бистәсендә яшәүчеләргә бу гадәти кагыйдә соңгы вакытта кулланылышка керә алмады.

Безнең инде чүп реформасы турында ишеткәнебез булгалады, хәтта аны өзлегеп көтсәк тә, чөнки калдык-постыклардан арыну өчен моңа хәтле һәрдаим түләп тордык. Яңа контейнерлар куярлар дип тә өмет иттек, чүпне көне-сәгате белән чыгарырлар дигән уй белән яшәдек, ниһаять тирә-юнь чиста булачагына ышандык. Әмма Царицындагы чүплек вазгыяте тәртипкә керә алмады. Яңа савытлар куелмады, искеләре югалды, көнкүрештән җыелган калдыкларны җыйнау урыннарын юкка чыгардылар. Дөрес, хәзер күнегелгән бу урыннардан чүп пакетларын җыеп, махсус машиналар йөри. Болай әйбәт тә кебек, ләкин ул машиналарны тоту, туры китерү мәсьәләсе бик авыр: кайбер урамнарга алар кереп тә тормыйлар, кергән чакта да бик тиз үтеп китәләр... Чүп капчыклары күтәреп, артларыннан чабып йөрү – үзе бер мәзәк. Шуның нәтиҗәсе булып, юл һәм урам кырыйларында электән күнегелгән чүп манзаралары хасил булды.

Царицын бистәсендә яшәүчеләр.

КАЗАН

КАР БӘЛАСЕ

Хөрмәтле редакция! Быелгы карлы ел гадәттәгечә коммуналь хуҗалык хезмәткәрләрен генә гаҗәпләндермәде. Менә, мәсәлән, без – Зур Клыки бистәсенең Костин урамында яшәүчеләрне дә. Карның күплеге икеләтә артык булды. Кар җыештыручы машиналарның хезмәтен цивилизация игелеге дип аңласак та, алар безне бик шатландырмыйлар, ә монда көтмәгән җирдән кышка булышлык күрсәткәндәй, күршедәге төзүчеләр килде. Әллә ни уйлап тормыйча, сәүдә үзәге төзелергә тиешле мәйдандагы карны безнең урамга ташый башладылар. Тротуар инде күмелде, яшел зона һәм урам юлына түгәргә тотындылар. Ике яклы юл тиз арада бер тар полосага әйләнде. Хәзер урамга керү-чыгу мәхшәргә әверелде. Ни чаклы ныграк ризасызлык белдерсәк, тагын да катырак ачу белән ташыйлар, инде кар өемнәре тау кадәр булды. Күрәсең, барысы да яз кояшының чара күрүен көтә...

Костин урамында яшәүчеләр.

КАЗАН

АДАШКАН ФИКЕРЛӘР

Без әчкәнгә күрә генә икътисад аягында басып тора..

Хатын-кызның сүзе тәненнән аерым йөри.

Яшен яшьнәмичә метеоролог прогноз ясамый.

Әгәр егермедә өйләнмичә калгансың икән, аннан соң иртә булачак.

Алма урлаучы агачыннан ерак төшми.

Җүләрләр өйләнә, акыллылар кияүгә чыга..

Тиздән заправкалардагы бензин сыеклана башлаячак – машина йөртүчеләрнең күз яшьләреннән.

Әгәр хатының сине бәдбәхет дип атаган икән, димәк, син барысын да дөрес эшләгәнсең.



Һади Такташ – узган гасырның татар шигърияте күгендәге иң якты йолдызларның берсе. Шагыйрьнең егерменче елларда Галиәсгар Камал, Кави Нәҗми, Гадел Кутуй кебек күренекле шәхесләр белән аралашуы, «Чаян» журналында җаваплы секретарь булып эшләве турында күпләр беләдер. Аның «Мәхәббәт тәүбәсе», «Килачәккә хатлар» кебек әсәрләрен укымаган, «Мокамаен» яттан белмәгән кеше юктыр. Болары, кем әйтмешли, классика. Әмма шагыйрьнең бүгенге укучыга таныш булмаган әсәрләре дә җитәрлек. Бөек әдипнең тууына 120 ел тулуга багышлап, укучыларыбыз белән Такташның төрле елларда, иҗади биеклекләр яулау юлында язган шигырьләрен искә төшереп алырга булдык.

ЮАНУ

Мин яралдым серле моңнарым белән
Бар дөньяны еглатырга;
Әйе, миндә көчле
Байроннар җаны.
Көн килер, күз яшьләрем тормыш күгендә ялтырар...
Дәртле җырларым моңыннан ил елар...

1921

КЫР КАЗЛАРЫ

Кыр казлары бүген җылы яктан
Һава ярып, тезлеп үттеләр.
Алар миңа карап киттеләр...
– Кыр казлары, безнең урмандагы
Җылы күлгә барып төшегез,
Җәйгә анда мине көтегез...
Кайтсам, тирән күлнең ярларына,
Камышлыкка капкын куярмын,
Эләксәгез, тотып суярмын!..
Кыр казлары, зинһар, мактанмагыз,
Ерак түгел безнең арабыз,
Сез очсагыз, без дә калышмабыз,
Әле
Сезне узып оча алабыз.
Еллар үтәр — менә күрерсез:
Фәнне эшкә җигә белербез,
Күктә гүләйт итеп йөрербез!..

ЧИСТА БУЛ!

(кыскартылып бирелә)

Дус егетләр, иптәш кешеләр,
Тагын шуны белегез:
Маневрда йөргән чакта,
Чиста килеш йөрегез!

...

...Их Абдулла, булыр микән
Акылланыр көннәрең?
Ял иткәндә ял итмисең,
Азып үтә төннәрең.
Иртә белән юлга чыккач,
Йоклый-йоклый барасың;
Бозау кебек ава-түнә
Һаман артта каласың...
Тәмәке тартканны күрсәң,
«Сорок» сорап аласың,
Очын да өзеп ташламый,
Авызыңа кабасың...
Их Абдулла, булыр микән
Акылланыр чакларың?
Бөтен полкта синнән начар
Армеецны тапмадым.

Йөргән чакта сулышыңны
Аузың белән аласың,
Шуның өчен дүрт чакрым да
Бара алмый арасың...
Атнада бер битең юсаң,
Анда да белдертәсең,
Кеше сөлгесенә, алып,
Йөзләреңне сөртәсең...

Хатын-кызлар очрап куйса,
Кемлегенә карамый,
Дусланасың... үбешәсең...
Безобразие!.. Ярамый!
Их Абдулла, болай йөрсәң
Күп аурулар алырсың,
Исән башың һәлак булыр,
Калек(а) булып калырсың...

1927

ГЫЙСЬЯН

(өзек)

Йорт караңгы, бар да исрек,
Зур кабак дөньясының
Мәйданында – муллалар, поплар,
Түрендә – зур санәм.
Тантана, мәҗлес кабакта,
Тук аюлардай булып,
Джентльменнар, мадмуазельләр
Гөр килеп, җырлап, дулап,
Зур кабакның уртасында
Туйлыйлар...
Ул философлар,
Әдипләр
Ниндидер сер уйлыйлар,
Уйлыйлар:
– У-у-у...
«Дин» диләр,
«Әхлак» диләр,
«Сәнгать» диләр –
Саф гакылларны агулап,
Зур хыянәткә, һәлакәткә
Халыкны димлиләр.

1923

ҮПКӘЛИМ

Октябрьгә менә ун ел тула,
Бер сайлаудан үзем калмадым,
Ләкин,
Күңел өчен генә дә бер,
Нарком булып үтә алмадым.
Нишлисең бит,
– Күңел шайтан, диләр,
Кайчак шулай күпкә киткәли.
Татарстан!
Синең ирекле җырчың
Бүген менә сиңа үпкәли...
Ни булса да инде дөресен әйтим,
Теләгемне аңламадыгыз,
Сайлау булды,
Көттем...
Инде бу юлы да
Нарком итеп сайламадыгыз!..
Ни була иде инде тик бер көнгә
Совнаркомны миңа бирсәгез,
Яки уйнап кына шунда
Күңел өчен:
– Нарком Такташ! –
Диеп йөрсәгез.
Инде калдым тагын атсыз гына –
Казан урамында чабарга,
Нарком аты үтеп киткән саен
(Басмасын дип)
Читтән генә куркып карарга...

1927



Лилия ФӘРХЕТДИНОВА

ҮЗИЗОЛЯЦИЯДӘ ОНЛАЙН-УКУ

Дөньядагы таҗвирус безнең илгә дә һөҗүм иткәч, президентыбыз быел барыбызга да өйдә утырырга кушты. Каникул вакытында урамга чыгып уйнамагач, бик күңелсез булган иде. Көендем шуңа... Каникул беткәч,мәктәпкә йөрисе түгел, өйдә торып кына укыйсын белгәч, сөендем шуңа! Рәхәт бит! Телисең, алма кимереп утырасың, телисең, сок суырып... Хет утырып укы, хет ятып дигәндәй. Беркем сүз әйтүче юк!!!


Менә дистанцион дәресләр башланып та китте. Әле ярар быел Кыш бабай миңа өч ел буе көткән планшетны бүләк итте. Ансыз өйдә торып уку юк икән бит. Дистант дәресләр миңа ошады. Элек әни: "Ташла телефоныңны! Урамга чыгып уйнап кер!" – дип тиргәсә, әти: "Анаңны тыңла, малай актыгы!" – дип җикеренсә, хәзер исә үзләре минем белән мониторга көне буе текәлеп утыралар, янәсе, миңа дәрес хәзерләшәләр. Дәрес вакытында әле бер платформага, әле икенчесенә, әле өченчесенә тоташасың. Кызык! Аннары әле берсе, әле икенчесе, әле өченчесе эштән чыга, йә ишелеп төшә, йә җимерелә. Кызганыч! Ярый әле бер-ике көндә рәтләнде болар. Югыйсә, надан каласым иде. Әби әйтмешли, тәүбә,тәүбә!

Миңа да, туганнарыма да аеруча укытучыларымның турыдан-туры эфирга чыгып үткәргән дәресләре бик ошады. Менә математика дәресе зумда башланды. Математиканы мин яратам, мисалларны да тиз чишәм. Планшет экранында Алсу апа күренүе булды, әти шундук : "Улым, булышыйм әле сиңа!" – дип, яныма ук килеп утырды, ә үзе Алсуападан күзләрен дә алмый. Укытучыбыз чибәр шул. Бүген беренче видеодәрес булгач, аеруча килешле, изүе ачык, алсу төстәге күлмәген кигән. Әни генә, төсе уңган халат итәкләрен төзәткәли-төзәткәли, тизрәк телефонын алып, мәктәп директорына шалтырата башлады. "Фәния Мәгърифәтовна! Нигә укытучыларыгыз шундый ачык изүле күлмәк кия? Сез, директор буларак, кая карыйсыз? Математика укытучыгызның ике "әфлисуны" планшет мониторыннан минем иремнең кулларына тәгәрәп төшеп бара ич!" – дип канәгатьсезлеген белгертте. Шалтыратуы да булды, дәрес тә тәмамланды.

Икенче дәрес физкультура икән. Аны Марат абый алып бара. Ул – чын спортчы. Аңа мәктәптәге барлык кызлар гашыйк. Ә без, егетләр, аңа охшарга тырышабыз. Бу дәрес тә онлайн икән. "Физкульт-привет, балалар! Тиз генә җылынып алыйк та, идәнгә ятып, үз гәүдәбезне үзебез күтәрик", – диде укытучы абый. Бу сүзләрне ишеткәч, әти аш бүлмәсенә юнәлде. "Ашарга әле берни юк," – дип, әни-әтине зур бүлмәгә куып чыгарды. Шул чакта планшет мониторында баһадир гәүдәсен идәнгә сузып яткан Марат абый күнегү ясап маташа иде. Әни, әтинең барлыгын да онытып, мониторга текәлде, чәчен рәтләгәндәй итте, аннары, кызарып: "Укытучы абыең кебек дөрес яса, малай актыгы!" – дигән булды. Әти, буш корсагын кашып, бер – әнигә, бер – абыйга, бер миңа карап алды...

Өченче дәрес немец теле иде. Гаиләбездә аны сугыш күргән бабабыздан башка беркем дә белми. Шуңа күрә планшетны күтәреп, бабай бүлмәсенә юнәлдем. Онлайн дәрес башланды. Экраннан безгә бабамның яшьтәше Нәфисә апа карый иде. Янында оныгы нишләргә, кая баскаларга кирәклеген аңлатып тора, чөнки Нәфисә апа техниканы без немецча белмәгән кебек үк белми иде.

Шул чакта әбием: "Балам, туган тел дәресе булса, мине чакырырсың, яме?" – диде. Ләкин әбигә ул дәресне шактый озак көтәргә туры килер, мөгаен, чөнки ул ике атнага бер генә була шул.



Игорь КИЙКО



САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 3 (1904) март 2021

Баш редактор: Р.И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ, Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 05.03.2021 ел.
Тираж – 3413 Заказ Е-600

Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!





1. Йоклар алдыннан көтелмәгән өянәк?

2. Адвокатның төп сыйфаты?

3. Нәрсә ул мәктәп?

4. Киң таралган чишендерү уены?

5. Ни өчен фармацевтлыкка озак укырга кирәк?

6. Ябыгу өчен диетага утыручыларның проблемалары нәрсәдә?

7. Ирләрнең теләге белән хатыннарныкы арасында нинди аерма?

ЖАВАПЛАР

1. Бирәнчек. 2. Бушка сөйләмәү. 3. Укучылар укытучыларга отчет язарга комачаулый торган урын. 4. Ипотека. 5. Өч еллы табиблар язган рецептны өйрәнергә генә ута. 6. Гел утырып торырга гына түгел, ә күбрәк йөрергә, хәтта йөгерергә кирәк. 7. Хатын теләге – закон, ә ир теләге – статья!

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Ринат АБЗАЛОВ төзеде

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда жыр исемен укыгыз. Журналыбызның 2021 елның 2 нче санындагы чаянвордның тикшерү сүзе – **«КАРЛАР ЯВА ТЫН ГЫНА»**


Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:
С. ГАЛИЕВА (Азнакай р-ны, Урманай ав.),
Н. НИКИТИНА (Чистай р-ны, Чуаш Ялтаны ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан),
Б.ШӘЙХЕТДИНОВ (Алексеевский р-ны, Урта Тигәнәле ав.).

Җиңүчебез – Урманайдан
Сиринә ГАЛИЕВА!



«Чаян»ның легендар рәссамы Борис Александрович СТАРЧИКОВның тууына 100 ел булды. Сугыш юлларын үтеп өенә кайтканнан соң, тыелган әдәбият саклаган өчен ул кулга алына һәм срок алгач, Коми АССРга эшкә җибәрелә. Төзелештә хезмәт итә һәм Микунь район бистәсендә Мәдәният йортын бизәү өстендә эшли. 1953 елда хокукларыннан мәхрүм ителеп, ирекккә чыккач, Казанга күчеп килә. 1959–1969 елларда «Чаян»ның сәнгать редакторы була. 1970 елда Мәскәүгә китә һәм анда «Крокодил» журналы редакциясендә эшли. Борис Старчиков татар халкына, аның нечкә юморына, Казанга булган мәхәббәтен гомере буе күңелендә саклый.





– Берничә нәни чыршы кисәргә рөхсәтебез бар...



4612750670080